Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

№ 75 **25.07.2022 ел**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештырунның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алынганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Карар дәүләт теркәве узганнан һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы **Л.И. Сибгатуллин**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге
Советының
25.07.2022 ел № 75
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктын өстәргә:
«9.1) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүттерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документациясенә яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү (алга таба - билгеләнгән таләпләргә туры китерү);»;
2. 47 статьяда:
а) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән (рөхсәтсез) төзелгән корылманы сүттерү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яки билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә.»;
б) 6 пунктта өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләрне үтәүне гамәлгә ашыра, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра;».